**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен гамәлгә кую турында**

Педагогик хезмәткәрләрне фәнни һәм фәнни-методика эшчәнлегенә кызыксындыру, Россиянең күренекле галим-педагогы һәм Көнчыгышны өйрәнү белгече, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе һәм Россия мәгариф академиясе академигы, Россия Федерациясенең Атказанган фән эшлеклесе Мәхмүтов Мирза Исмәгыйль улы исемен мәңгеләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен гамәлгә куярга.

2. Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитетын оештырырга.

3. Түбәндәгеләрне расларга:
Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясе турындагы нигезләмәне (1 нче кушымта);
Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты турында нигезләмәне (2 нче кушымта);
Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты составын (3 нче кушымта);
«Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясе лауреаты» дипломы тасвирламасын һәм бланк үрнәген (4 нче кушымта);
«Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясе лауреаты» мактау билгесенең тасвирламасын һәм сурәтен (5 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 2018 елдан башлап, әлеге Указны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауга Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бүлеп бирүне тәэмин итәргә.

5. «Фән һәм техника, мәгариф, мәдәният, әдәбият һәм сәнгать, массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә күренекле казанышларга

ирешкән өчен, салым түләүчеләр тарафыннан алына торган, салым салынырга тиеш булмаган суммалы бүләкләр исемлеген раслау турында» 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-651 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 22 сентябрендәге ПУ-913 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1014 номерлы, 2014 елның 7 ноябрендәге ПУ-1019 номерлы һәм 2016 елның 14 мартындагы ПУ-240 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Фән һәм техника, мәгариф, мәдәният, әдәбият һәм сәнгать, массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә күренекле казанышларга ирешкән өчен, салым түләүчеләр тарафыннан алына торган, салым салынырга тиеш булмаган суммалы бүләкләр исемлегенә, аңа түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«9. Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясе.».

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 26 декабрь
№ ПУ-1169

Татарстан Республикасы
Президентының
2017 елның «26» декабрендәге
ПУ-1169 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясе турындагы нигезләмә**

1. Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясе (алга таба – М.И. Мәхмүтов исемендәге премия) дидактика, педагогик кадрлар әзерләү өлкәсендәге алдынгы фәнни-методик һәм гамәли казанышлары, нәтиҗәле технологияләрне белем бирү процессына кертүләре өчен Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәгариф оешмалары педагогик хезмәткәрләренә бирелә.

2. М.И. Мәхмүтов исемендәге премияне Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) тәкъдимнәре нигезендә Татарстан Республикасы Президенты тапшыра.

3. Һәр елның 5 октябренә туры китереп һәрберсе йөз мең сум күләмендә М.И. Мәхмүтов исемендәге ике премия тапшырыла.

4. М.И. Мәхмүтов исемендәге премиягә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәгариф оешмалары педагогик хезмәткәрләре тәкъдим ителә ала. Педагогик хезмәткәрләр коллективын М.И. Мәхмүтов исемендәге премиягә тәкъдим итү рөхсәт ителми.

5. М.И. Мәхмүтов исемендәге премиягә тәкъдим ителгән затның (алга таба – премиягә тәкъдим ителгән зат) документлары һәр елны 1 июльгә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәгариф оешмалары тарафыннан Комитетка карап тикшерү өчен тапшырыла.

6. Карап тикшерү өчен Комитетка премиягә тәкъдим ителгән затлар түбәндәге документлар тапшырырга тиеш:

а) премиягә тәкъдим ителгән затның җитәкченең имзасы һәм оешманың мөһере белән расланган белешмә кәгазе;

б) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе;

в) премиягә тәкъдим ителгән затның шәхесен таныклаучы документның күчермәсе;

г) премиягә тәкъдим ителгән затның һөнәри белем алуын раслаучы документ күчермәсе;

д) премиягә тәкъдим ителгән затның эш нәтиҗәләрен күрсәтүче документлар (белешмәләр, бәяләмәләр, эксперт бәяләмәләре, рецензияләр яисә башка документлар);

е) фәнни басмаларда чыккан, белешмәләр базаларында реферат буларак урнаштырылган мәкаләләрнең беренче битләре күчермәләре һәм монографиянең титул бите һәм титул битенең нәшрият турындагы мәгълүмат күрсәтелгән икенче ягы (булган очракта);

ж) фәннәр кандидаты һәм (яисә) фәннәр докторы дипломының күчермәсе (булган очракта);

з) тапшырылган документлар исемлеге.

7. Премиягә тәкъдим ителгән затларның документларын кабул итү тәмамланганнан соң, Комитет аларны алдан карап тикшерә һәм аның йомгаклары буенча эксперт комиссиясе оештыру, аның составын һәм эш тәртибен раслау турында карар кабул итә.

Премиягә тәкъдим ителгән затларның тапшырылган документлары аларга бәяләмә бирү өчен эксперт комиссиясенә тапшырыла.

8. Комитет эксперт комиссиясенең бәяләмәсе нигезендә М.И. Мәхмүтов исемендәге премия тапшыруга кагылышлы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Президентына бирү турында карар кабул итә һәм 1 сентябрьгә кадәр аларны Татарстан Республикасы Президенты каравына тапшыра.

9. М.И. Мәхмүтов исемендәге премиягә лаек булган затларга «М.И. Мәхмүтов исемендәге премия лауреаты» дигән исем бирелә һәм аларга тантаналы шартларда акчалата бүләк, диплом һәм мактау билгесе тапшырыла.

10. Дипломнарны, мактау билгеләрен әзерләүне Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе оештыра.

11. М.И. Мәхмүтов исемендәге премиягә тәкъдим ителгән затлар арасында аңа лаек кандидатлар булмаган яисә тәкъдим ителгән затлар саны ел саен тапшырыла торган премияләр санынннан азрак булган очракта, шуңа бәйле рәвештә премияләр бирелми яки азрак санда бирелә.

12. М.И. Мәхмүтов исемендәге премияне тапшыру тантанасын әзерләү һәм уздыруны оештыруны һәм техник яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы башкара.

Татарстан Республикасы
Президентының
2017 елның «_26_» _декабрендәге_
ПУ-_1169_ номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты турында нигезләмә**

1. Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен (алга таба – М.И. Мәхмүтов исемендәге премия) бирү буенча чараларны әзерләү һәм уздыруны оештыру максатларында төзелде.

2. Комитет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясе турында нигезләмәгә, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комитетның төп бурычы булып М.И. Мәхмүтов исемендәге премиягә тәкъдим ителгән затларның хезмәтләрен карап тикшерүне оештыру һәм М.И. Мәхмүтов исемендәге премия тапшыру турында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Президентына тапшыру тора.

4. Комитетның функцияләре:

М.И. Мәхмүтов исемендәге премиягә тәкъдим ителгән затларның документларын карап тикшерү;

эксперт комиссиясе эшен оештыру, аның составын һәм эш тәртибен раслау;

эксперт комиссиясе карарларын тикшерү;

М.И. Мәхмүтов исемендәге премияне тапшыру турында Татарстан Республикасы Президентына тәкъдимнәр кертү;

5. Комитет түбәндәгеләргә хокуклы:

законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук фәнни һәм башка оешмалардан Комитет карамагындагы мәсьәләләр буенча материаллар һәм мәгълүмат соратырга;

Комитет компетенциясенә кергән мәсьәләләрне хәл итү өчен эксперт комиссиясе төзергә;

билгеләнгән тәртиптә Комитет эшчәнлегенә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, югары белем бирү мәгариф оешмалары, шулай ук фәнни һәм башка оешмалар вәкилләрен җәлеп итәргә.

6. Комитетның вазыйфалары:

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан фәнни һәм мәгариф оешмалары белән М.И. Мәхмүтов исемендәге премияне бирү мәсьәләләре буенча үзара эшчәнлекне оештыру;

эксперт комиссиясе эшен мәгълүмати һәм оештыру-техник яктан тәэмин итү;

эксперт комиссиясе карарларын үз вакытында карап тикшерү һәм Татарстан Республикасы Президенты каравына М.И. Мәхмүтов исемендәге премияне тапшыру турында тәкъдимнәр бирү.

7. Комитет составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

8. Комитет составына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгатьчелек, мәгариф оешмалары, фәнни һәм башка оешмалар вәкилләре кертелә.

Комитетның барлык әгъзалары үз эшчәнлеген түләүсез нигездә башкара.

9. Комитет утырышлары кирәк булган саен, ләкин елга кимендә ике тапкыр уздырыла һәм, әгәр дә аларда Комитет әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, гамәлгә хокуклы дип санала.

10. Комитет эшчәнлегенә – Комитет рәисе, ә ул булмаганда Комитет рәисе урынбасары җитәкчелек итә.

11. Комитет рәисе Комитет эшен планлаштыра, Комитет утырышларын билгели һәм алып бара.

12. Комитет секретаре Комитет рәисе тарафыннан Комитет әгъзалары арасыннан билгеләп куела.

13. Комитет секретаре Комитет утырышларын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру эшләрен һәм техник эшләрне башкара, шул исәптән премиягә тәкъдим ителгән затларның Комитет каравына кертелгән документларын тикшерә, шулай ук Комитет утырышлары беркетмәләрен әзерли.

14. Утырышта катнашучы Комитет әгъзаларының яртысыннан күбрәге аларны хуплап тавыш бирсә, Комитет карарлары кабул ителгән дип санала. Тавышлар саны тигез булганда, Комитет рәисе тавышы хәлиткеч булып санала.

15. Комитет карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа Комитет секретаре имза куя һәм ул утырышта рәислек итүче тарафыннан раслана.

16. Комитет эшчәнлеген оештыру-техник яктан һәм финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы Мәгариф һәм министрлыгы тарафыннан тормышка ашырыла.

Татарстан Республикасы
Президентының
2017 елның «_26_» декабрендәге
ПУ-1169 номерлы Указына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты составы**

| | |
|---|---|
| Борһанов Рафис Тимерхан улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры вазыйфаларын башкаручы, Комитет рәисе |
| Сәлахов Мәкъзүм Хәлимулла улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты, Комитет рәисе урынбасары |
| Бәдриева Рина Ринат кызы | Татарстан Республикасының Мәгарифне үстерү институты ректоры (килешү буенча) |
| Вәлиев Разил Исмәгыйль улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Җәләлова Анфиса Григорьевна | Казан педагогика көллияте директоры, Татарстан Республикасы урта һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләренең Директорлар советы рәисе (килешү буенча) |
| Минзарипов Рияз Гатаулла улы | Казан (Идел буе) федераль университетының беренче проректоры (килешү буенча) |
| Мостафина Фәйрүзә Зөфәр кызы | Чаллы дәүләт педагогика университеты ректоры (килешү буенча) |
| Мөхәммәтҗанова Фәридә Шамил кызы | Россия мәгариф академиясенең Һөнәри белем бирү педагогикасы һәм психологиясе институты директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Парфенов<br>Вячеслав Викторович | Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының 6 номерлы аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры (килешү буенча) |
| Прохоров<br>Юрий Петрович | Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре һөнәр берлегенең Татарстан республика иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Фазлыева<br>Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе |
| Һадиуллин<br>Илсур Гәрәй улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Хафизов<br>Рәшит Салих улы | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Пәрәү урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры (килешү буенча) |
| Шакирова<br>Диларә Мансур кызы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе «Гамәли семиотика» фәнни-тикшеренү институтының интеллектуаль потенциал һәм сәләтлелек лабораториясе мөдире (килешү буенча) |

Татарстан Республикасы
Президентының
2017 елның «26» декабрендәге
ПУ-1169 номерлы Указына
4 нче кушымта

**«Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясе лауреаты» дипломы тасвирламасы һәм бланк үрнәге**

«Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты» дипломының бланкы тыгызлыгы 100 г/м$^2$ булган, 25 % мамык җепселле, оптик агартусыз югары сыйфатлы кәгазьгә басыла.

Диплом бланкы 220 мм × 160 мм зурлыгында, вертикаль урнаштырылган кәгазь бите рәвешендә була, фоны ак төстә.

Бланкның уртасында кара төстә (Times New Roman Italic шрифты белән, 11 п. кегльдә) ике телдә – татар һәм рус телләрендә – түбәндәге язма бастырыла:

*«Татарстан Республикасының*
*М.И. Мәхмүтов исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты*
***ДИПЛОМЫ***

*Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә*
*____ елның М.И. Мәхмүтов исемендәге Дәүләт премиясе*
*___________________________________бирелде».*

Язмадан астарак ике телдә – татар һәм рус телләрендә – имза урнаштырылган, ул «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләреннән, Татарстан Республикасы Президентының исеме инициалыннан, атасының исеме инициалыннан һәм фамилиясеннән тора.

*Татарстан Республикасының*
*М.И. Мәхмүтов исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты*
***ДИПЛОМЫ***

*Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә*
*____ елның М.И. Мәхмүтов исемендәге Дәүләт премиясе*
*______________________________ бирелде*

*****

***ДИПЛОМ***
*лауреата Государственной премии Республики Татарстан*
*имени М.И. Махмутова*

*Указом Президента Республики Татарстан*
*Государственная премия Республики Татарстан имени М.И. Махмутова ____ года*
*присуждена*
*______________________________________________________*

*Татарстан Республикасы Президенты* — *Р.Н. Миңнеханов*
*Президент Республики Татарстан* — *Р.Н. Минниханов*

__________

Татарстан Республикасы
Президентының
2017 елның «  26  » декабрендәге
ПУ-1169 номерлы Указына
5 нче кушымта

**«Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясе лауреаты» мактаулы билгесенең тасвирламасы һәм сурәте**

«Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясе лауреаты» мактаулы билгесе куе алтынсу төстәге металлдан коела һәм 32 мм диаметрлы түгәрәк формасында була.

Мактаулы билгенең алгы ягында уртада академик М.И. Мәхмүтов портреты төшерелгән.

Мактаулы билгенең икенче ягында уртада «За научно-практические достижения в образовании» язмасы урнаштырылган. Мактаулы билгенең кырыйлары рельефлы чыгынты белән каймаланган. Мактаулы билгенең алгы ягындагы чыгынтыда рус телендә баш хәрефләр белән язылган текст урнаштырылган: «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ПРЕМИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ИМЕНИ М.И. МАХМУТОВА». Мактаулы билгенең икенче ягында чыгынтыда татар телендә баш хәрефләр белән язылган текст урнаштырылган: «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ М.И. МӘХМҮТОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ». Мактаулы билгенең бөтен сурәтләре рельефлы.

Мактаулы билге яшел-ак-кызыл төсләрдән – Татарстан Республикасы Дәүләт флагы төсләреннән торган ефәк тасма белән тышланган дүртпочмаклы колодкага элмәк һәм бождра ярдәмендә беркетелә. Колодканың озынлыгы – 26 мм, киңлеге – 15 мм. Тасманың озынлыгы – 23,5 мм. Кызыл һәм яшел төстәге полосаларның киңлеге – 5,3 мм, ак полосаның киңлеге – 1,3 мм.

Мактаулы билге футлярга салынган.




---